Дөнья сиңа елмайсын дисәң, үзең аңа елмаеп кара!

Джон Э.Смит

ДЕКАБРЬ
2013 ел
№3

# КӨМЕШ КЫҢГЫРАУ

ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КЕЧЕ КИБӘХУЖА ТӨП МӘКТӘБЕ

## Хуш, иске 2013 ел - Елан елы!
## Исәнме, яңа 2014 ел - Ат елы!





Яңа еллар килсен бәхет алып,
Яңа еллар килсен елмаеп,
Күңелләрдә мәңге шатлык булсын,
Яшәмәгез дуслар моңаеп.

Котлы булсын Яңа ел!
Гел шатлыктан торсын ул,
Бәхетле һәм мул тормышка
Курсәтсен ул яңа юл.

## 2013-2014 уку елы Татарстан Республикасында Математика елы дип игълан ителде.

Математика фәне мәктәптә төп фәннәрнең берсе булып тора. Дәүләт йомгаклау аттестациясен дә (ГИА), бердәм дәүләт имтиханын да (ЕГЭ) беренчеләрдән булып математика фәне буенча керттеләр. Быел Арчада булган укытучыларның август кинәшмәсендә 2013-2014 нче уку елын Татарстан Республикасында Математика елы дип уткәрергә тәкъдим ителде. Тиздән ТР Мәгариф һәм фән министры приказы нигезендә “2013-2014 уку елы - ТР да Математика елы” дип игълан ителде. Мәгариф министрлыгы планы нигезендә без мәктәпнең Математика елын үткәрү планын төзеп, план нигезендә эшне башладык.

Декабрь аенда математика укытучылары Найлә Нуретдиновна, Гөлнур Әхмәтзәкиевна, башлангыч сыйныфлар укытучылары Гөлсинә Зөлфәровна, Тәслимә Миңнуровналар “Математика дәресенең иң яхшы методик эшкәртмәсе” республика конкурсына эшләр җибәрделәр.

Алга таба да математика укытучылары һәм укучылар өчен төрле конкурслар, турнирлар, олимпиадалар каралган. Аларның кайберләре дистанцион формада да үтәчәк.

Укытучылар өчен, үз эш тәҗрибәләрен башкаларга җиткерү максатыннан, методик җыентыклар чыгару күздә тотыла.

Укытучыларга һәм укучыларга бу чараларда актив катнашып, уңай нәтиҗәләргә ирешүләрен телибез.

****************************************

Президентыбыз - Миңнеханов Рөстәм Нургали улы, "2014 нче елда Татарстан Республикасында Мәдәният елы уздыру турында"гы боерыкны имзалады.
(№УП - 847, 29 август - 2013 ел).
Димәк, Татарстан Республикасында 2014 нче ел - Мәдәният елы булачак.

****************************************

## Яңа ел сынамышлары

**Яңа елдан башка бер генә бәйрәм дә сынамышларга болай ук бай түгелдер, чөнки ул бит ике елның алышыну көне...**

Кешеләр элек-электән бу ике көннең ниндидер күзгә күренми торган серле бәйләнештә торуын аңлаган. Бер ел икенче ел белән “көрәшә”, шулай да Яңа ел “җиңә”, дип ышанган, киләсе елда тормышның ничек булачагы бу көндәге бәйрәмгә бәйле, дип уйлаган. Яңа ел бәхет-шатлыклар алып килсен өчен, халык әйләнә-бәйләнә уйнаган, такмаклар әйтешкән, нинди генә киемнәр кимәгән. Шулай итеп, ниндидер ышанулар барлыкка килгән. Башка ил халкы кебек үк, Россиядә дә ышанулар “яшәгән”.

Кызлар өчен бу вакыт икеләтә дулкынландыргыч булган, чөнки алар кияү буласы кешенең кем булачагын ачыклаган. Яңа ел алдыннан кызлар мунча себеркесе белән өстәл астын себергән. Әгәр дә берәр ашлык бөртеге килеп чыкса, бу тиздән кияүгә чыгуны аңлаткан.

Киләсе елда барлык гаилә әгъзаләре сау-сәламәт булсын өчен, бәйрәм өстәле артында утырган кешеләр бер-берсенең аякларын бау белән бәйләгән. Шушы ук сынамыш гаиләнең тук һәм бер нәрсәгә дә мохтаҗ булмавы өчен дә кулланылган.

Алда әйтелгән борынгы ышанулар инде онытылган, шулай да кайбер сынамышлар бүген дә яши бирә. Аларның берничәсен искә төшереп китик:

1. Яңа елны күңелле итеп, яхшы кешеләр белән каршы алырга кирәк. “Яңа елны ничек үткәрәсең, елың шулай була”, диләр бит.
2. Бәйрәм алдыннан беркемгә дә акча биреп торырга, шулай ук бурычны кайтарырга ярамый. Бу ел буена “кредит корты” булуга китерергә мөмкин.
3. Ә менә Яңа ел төнендә төчкерү бик әйбәт билге: ул ел буе бәхетле булуны искәртә. Бәхетле булу өчен ирексезләп төчкерсәң дә ярый.
4. Бәйрәмгә яңа, матур кием кисәң, ел буе киемең белән мактана алачаксың икән.
5. Әгәр дә киемегездә кесә күп икән, һәрберсенә акча салырга кирәк. Аның ничә сум булуы мөһим түгел, бары буш кына булмасын.
6. Өстәлегезгә ипи-тоз куярга онытмагыз, шулай ук ашамлыкка тотылган акчаны санамагыз: табын мулрак булган саен яхшырак.
7. Төрле-төрле баллы җимешләр сатып алыгыз. Алар 12 төрле булсын. Һәрберсен берәр ай исемен атап, тешләп булса да чыгарга кирәк. Бу “хезмәт” алдагы бер ел “татлы, баллы” булсын өчен эшләнә.

*Материалны туплаучы: Аскаров Данис*

ГОД ЭКОЛОГИЧЕСКОЙ КУЛЬТУРЫ И ОХРАНЫ ОКРУЖАЮЩЕЙ СРЕДЫ В РЕСПУБЛИКЕ ТАТАРСТАН

**“2013 ел – Татарстан Республикасында экологик культура һәм әйләнә-тирә мохитне саклау елы”**

**нәтиҗәләре**

Әйләнә-тирә мохитне саклау һәм укучыларда экологик культура тәрбияләү максатыннан 2013 елда мәктәбебездә бик күп чаралар үткәрелде.

Мәктәп сайтыннан:



20 март көнне Арча шәһәрендә Татарстанда экологик культура һәм әйләнә- тирә мохитне саклау елы кысаларында "Кеше һәм табигать" республика фәнни-гамәли конференциясе булып үтте. IX сыйныф укучысы Кәримуллина Диләрә үз номинациясендә II урынны алды. (Җитәкчесе: Закирова Г.М.)




В г. Арске республиканской научно- практической конференции "Человек и природа", участвовала ученица VIII класса Сафиуллина Илюза и за активное участие получила Диплом. Её руководитель Арсланова И.М.



**Экологик викторина** 11.04.2013

Мәктәптә башлангыч сыйныф укучыларының "Әйләнә - тирә дөнья "атналыгы дәвам итә.

Бүген Гарипова Г.З. 1- 4 сыйныф укучылары өчен "Экологик викторина" үткәрде. Укучылар 2 командага бүленеп көч сынаштылар.




**Табигатьне саклау - тормышны саклау**

12.04.2013

Башлангыч сыйныфлар укытучысы Асманова Т.М. "Табигатьне саклау - тормышны саклау" темасына балалар иртәсе үткәрде.



15.04 - 15.05 Мәктәптә экология айлыгы бара. Айлык барышында әйләнә - тирә мохитне саклау, чистарту, табигатьне саклау буенча чаралар планлаштырыла.




**СИН - табигать баласы.** 15.05.2013

Бүген мәктәбебездә шул тема астында Экология дәресе үткәрелде. Мәктәпнең укыту планыннан тыш үткәрелә торган бу дәресне мавыктыргыч итеп биология һәм география укытучысы Ф.Г.Әскарова үткәрде.

******************************************

Әйләнә – тирә мохитне саклау чаралары җәйге каникул чорында да дәвам итте. Без чишмә тирәләрен һәм елга буйларын чистарту эшләрендә катнаштык. Йорт-җир тирәсен, капка төбен, урамнарны чиста тоту буенча әти-әниләребезгә чистарту эшләрендә булыштык.

2013-2014 нче уку елында экологик чараларыбыз шулай ук дәвам итте. Көз көне мәктәп бакчасында, йорт тирәләрендә агачлар утырттык. Төрле экологик конкурсларда катнашуыбызны дәвам итәбез.

20 декабрьдә Флүзә Гайсиновна мәктәптә “Чисталык дәресе” үткәрде. Аның сөйләгәннәреннән җир шарының бик тиз чүпкә батып баруын, әгәр дә шулай дәвам итсә, экологик катастрофалар килеп чыгачагын аңладык. Ул безне экологик яктан культуралы булырга, әйләнә-тирә мохитне саклау эшен системалы башкарырга чакырды.

*Сәхифәне әзерләүче: Сафиуллина Илүзә*




**“Табигатьне саклагыз”.** Бу сүзләрне без бик еш ишетәбез. Әмма, аларның чын мәгънәсен без аңлап бетерәбезме икән? Һәрвакытта да аңлап бетермибез шул. Ә бит бу сүзләргә киләчәгебез турында зур мәгънә салынган.

Туган як табигате – чиста һава һәм экологик яктан чиста ашамлыклар гына дигән сүз түгел әле ул. Ул – Туган илебезнең матурлыгы да, җаны да. Туган илебезнең чиста сулы елга һәм күлләрен пычрату, очсыз-кырыйсыз урманнарны бер мәгънәсез кисеп бетерү, химия заводларының агулы газлары белән чиста һавабызны бозып бетерү – болар әле хәзерге цивилизациянең туган ягыбыз табигатенә салган зыянының бер өлеше генә. Табигатьне пычратучылар белән көрәшне без бүгеннән үк башламасак, берничә дистә елдан соң, бөтен тереклек көеп беткән чүл уртасында калуыбыз бар бит. Ул вакытта инде противогаз кимичә сулап та булмас, радиациядән саклый торган скафандрлар киеп яшәвебез дә бик ихтимал. Бу турыда фәннең төрле өлкәләрендәге атаклы белгечләр – биологлар, экологлар, химиклар, астрофизиклар, метеорологлар безне хәзер үк кисәтә.

Ә бит әле туган як табигате ул – калкулыктагы кипкән печән эскертләре арасындагы каен агачлары да, тынлык һәм хуш исләр белән тулган чыршы урманы да, иң кызу җәй көннәрендә дә салкын һәм көмештәй саф сулы күлләр дә, кечкенә генә инештән башлап, зур елгага таба ыргылучы елгачыклар да.

**Әйдәгез, һәрберебез, булдыра алганча, туган табигатьне саклыйк!**

**"Миннән соң су басса да ярый" дип яшәмик, киләсе буыннар безгә рәхмәт әйтерлек булсын.**

# Коррупциягә - юк!

Ай дәвамында шушы девиз астында мәктәптә һәм районда төрле чаралар үткәрелде. Безнең укучылар бу темага плакатлар ясап, мәктәптә күргәзмә оештырдылар. Яхшы эшләр район конкурсына да җибәрелде.



**Без коррупциягә каршы!** 09.12.2013

Бүген мәктәбебездә коррупциягә каршы игълан ителгән атналык кысаларында "9 декабрь- коррупциягә каршы көрәш көне" дигән баш астында дәресләр булып үтте. Башлангыч сыйныфлардан башлап, яшь үзенчәлекләреннән чыгып, сыйныф җитәкчеләре балаларга коррупциянең нәрсә икәнлеген, аңа каршы көрәш чараларын, законнарны аңлаттылар, җәмгыятьтә киң җәелгән бу күренеш корбаннары булмаска кирәклеген кисәттеләр. (Мәктәп сайтыннан)

"Коррупциягә – юк!" темасына районда һәм республикада сочинениеләр конкурсы да булды. Бу конкурста Арсланова И.М. җитәкчелегендә VIII сыйныф укучысы Даутова Дилбәр, Хуҗина Н.Ю. җитәкчелегендә IX сыйныф укучысы Закиров Рөстәм үз сочинениеләре белән катнаштылар.

*Закиров Рөстәм сочинениесеннән:*

... Игътибар белән тирә-якка күз салыйк әле: кемнәр кайда утыра һәм алар кемнең кеме? Безнең илдә дә җитәкчелекнең әтисеннән – улына, туганыннан – туганга, әшнәсеннән әшнәгә күчү очраклары аз түгел. Бу минем фантазиям түгел, интернетта казынып, мин моның шулай икәнлегенә шактый төшендем. Власть тотучыларның балаларына, туганнарына, минемчә, дипломлы булу мөһим дә түгел бугай. Аларны югары уку йортында укыганда ук шактый гына югары вазыйфага билгелиләр, диплом алуга инде тагын да югарырагы көтә. Кыска гына вакыт үтә, бу блатлы малайны бик тә югары властька менгереп тә утыртталар. Ә алар күп очракта сәләтсез. Биш ел буена үз көче белән тырышып укыган, белемле, яшь белгечләр азмыни бездә! Власть кәнәфиен билэп кенә эш барып чыкмый, минемчә. "Әзергә-бәзер булып үскән" яшь власть вәкилләрендә җитди, уйланылган карарлар кабул итү җитеп бетми, дип уйлыйм мин. Власть сатылмасын, җаваплы вазыйфаларга талантлы, алга карап уйлый белүче җитәкчеләр билгеләнсен иде.

Мин сәясәттән ерак торам. Властьның сатылучанлыгы турында шактый уйландым. Һәм мин шундый нәтиҗәгә килдем: бу эшнең башында ришвәтчелек тора. Ил, республика матбугатын укып барсаң да, җәмгыятебездә ришвәтчелек чиренең көннән-көн үсүен, ныгый барганын күрергә мөмкин.

Әйе, армиядән калыйм дисәң дә, шифаханәдә тиешенчә дәваланыйм дисәң дә, теге яки бу төр бәйгеләрдә җиңим дисәң дә, җинаять җаваплылыгыннан котылу өчен дә акча кирәк.

Якын туганыбыз авырып киткәч, әти-әнисенең Казан шифаханәләренең берсендә дәвалату өчен күпме түләгәннәрен ишеткәч, күзләребез "маңгайга менде". Конверт эчендәге акчаларның бу очракта ярдәме тиде.

Сәнгать, спорт бәйгеләренә дә тәэсир итә ришвәт. Сәләтсезләр призлы урыннар яулый, ә чын талантлар түбәндәге баскычта кала.

Ришвәтчелек тормышның барлык өлкәләрендә дә үз эшен эшли.

... Йомгаклап, шуны әйтәсем килә: власть сатылмасын өчен һәркем үз эшен намус белән башкарсын иде. Күңел биреп һәм вөҗданы кушканча...

*Даутова Дилбәр сочинениесеннән:*

**...** Коррупция,- читаю я в Википедии,- (от латинского «растлевать») – это использование должностным лицом своих полномочий в целях личной выгоды. Исследования ВЦИОМ показали, только 38 % россиян считают, что суд эффективное средство защиты прав, 36% в этом сомневаются, а еще 23% затруднились с ответом. На практике получается, что отнюдь не каждый, нарушивший закон и привлеченный к уголовной ответственности, может понести реальное наказание! Значит, если я хорошо материально обеспеченный бизнесмен или госслужащий, или, говоря простыми словами «новый русский» - то делаю то, что хочу, и уверен, что мне за это ничего не будет, что мои деньги решат все мои проблемы! И зачем тогда нам суды и какие-то законы вообще? Просто нужно найти «виновного», того, кто не имеет к данному делу никакого отношения, кто не может откупиться. На худой конец, можно «замять» любое дело как-нибудь…

… Мы все искренне надеемся на наш «справедливый суд». К сожалению, переступив порог здания суда, мы слишком часто теряем надежду. Никто не хочет оказаться виновным, и тогда каждый начинает искать какие-то пути к разрешению проблемы. Чаще всего, эти пути приводят к деньгам, к взяткам, в итоге мы начинаем думать, что если судья взял, значит, все будет в порядке. Лишь малое количество людей реально задумывается о том, что все это совершенно неправильно. В обществе формируется стереотип поведения, который передается из поколения в поколение.

Следовательно, виновниками коррупции в правоохранительных органах являются не только сами судьи, но и мы, граждане. Вполне понятно, когда человек жалобно смотрит в глаза адвокату или судье и просто умоляет сделать хоть что-нибудь, при этом предлагая деньги… Что ж тут можно поделать?.. Я, честно говоря, не знаю ответа на этот вопрос, но, с другой стороны, не хочу, чтобы росла коррупция в судах.

…

# Күршебез Раил абый - дөнья чемпионы!

Безнең күршедә билбау көрәше буенча күп мәртәбәләр Татарстан Республикасы һәм Россия Федерациясе чемпионы булган Нургалиев Раил абый яши. Үзенең тырышлыгы, максатка ирешүчәнлеге нәтиҗәсендә ул шундый уңышларга ирешкән. Раил абый өйләрендә сирәк була, чөнки ул һәрвакыт юлда, ниндидер ярышларга катнашырга китә. Ул кайткан вакытларда мин аның белән очрашырга тырышам. Аның ярышларда алган бүләкләрен: дипломнар, кубоклар, медальләрен карыйм.

Уйлап карасаң, Раил абый безнең кебек үк авыл баласы бит. Ул да без эчкән суны эчеп, без сулаган һаваны сулап үскән, безнең мәктәптә белем алган, хәтта сыйныф җитәкчеләре дә безнең Гөлнур апа булган. Ул Казан дәүләт педагогика университетының физик тәрбия факультетын тәмамлап, туган ягына тренер булып эшкә кайткан.

Быел ноябрь аенда Раил абый Башкортстанның Салават шәһәрендә булган билбаулы көрәш буенча дөнья чемпионатында җиңеп, дөнья чемпионы исемен алды. Без аны бу зур җиңүе белән тәбрик итәбез.

Мин Раил абый белән горурланам, аннан үрнәк алам. Раил абый турында intertat.ru электрон газетасында чыккан мәкаләне тәкъдим итәм.

# *Татарстан билбаучыларының зур уңышы*



Күптән түгел Башкортстанның Салават шәһәрендә билбаулы көрәш буенча унберенче дөнья чемпионаты үтте. "Нефтехимик" спорт сараенда узган ярышларда дөньяның 35 иленнән иң көчле көрәшчеләр бил алышты. Бәйгедә Россия көрәшчеләренә тиңнәр табылмады: ватандашларыбыз 19 мөмкинлектән 18 алтын медаль яулауга иреште. Ошбу уңышка Татарстан вәкилләре дә зур өлеш кертте. Билбаулы көрәшнең иркен стилендә Габделҗәлил Сөләйманов – беренче, Гөлия Хәбибуллина икенче урында. Классик төрдә исә Марат Гарипов, Раил Нургалиев һәм Илдар Аббасов алтын медальләргә лаек булды. Чагыштыру өчен: мәйдан хуҗалары исәбендә ике генә алтын медаль.

Дөнья чемпионатыннан кайткач, Intertat.ru хәбәрчесе чемпионнарыбыз Раил Нургалиев һәм Илдар Аббасов белән аралашып алды.

**Тәүге тапкыр чемпион**

Татарча көрәштә Теләче батыры Раил Нургалиевны белмәүче кеше юктыр. Атказанган спорт остасы милли төребез буенча барлык дәрәҗәле бәйгеләрне дә отып бетерде. Әмма билбаулы көрәштә әле ул үзен беренче тапкыр гына күрсәтте. Салаватта җиңү яулап, Раил шунда ук Россиянең халыкара класслы спорт исеменә лаек булды. Милли көрәштән Атказанган исеменә лаек булган 27 яшьлек Нургалиев шул ук исемне билбаулы көрәштән дә алу турында хыяллана.

Раил чыгыш ясаган 100 кг га кадәр авырлык үлчәвендә, татар көрәшендәгечә, гаять көчле көрәшчеләр тупланган. "Призлы урыннарны алган егетләрнең барысы да төрле илләрдә чемпион калган егетләр", - ди көндәшләре турында Теләче батыры. Финалда көрәшергә туры килгән Анатолий Молдованны (Молдовия) казанлылар да хәтерлидер әле. Бик тә көчле көрәшче Татарстан башкаласына дөнья чемпионатына да килде, Универсиадада да бронза медаль яулады.

Р.Нургалиев сүзләренә караганда, спортның әлеге төрендә ниндидер бер алым белән генә җиңеп булмый. "Кемдер "прогиб" куллана, кемдер "через бедро" бәрә", - ди ул. "Син исә татарча итеп көндәшеңне күтәреп кенә бәрәсеңдер?" – дигән соравымны Раил болай җаваплый: "алай гына булмый шул, күтәреп бәргәндә кайсыдыр "накрывать" итеп арканя ятсаң, шунда ук җиңелгән буласың". Көрәшче шулай ук әлеге уңышына бөтен авыл, бөтен Теләче шатлануын, берничә көн дәвамында шалтыратып котлауларын, Теләче башлыгы Илдус Зариповның шәхсән тәбрикләве хакында да искәртте.

*Дөнья чемпионы Нургалиев Раил белән Миннебаев Мөнәвир таныштырды.*

## Декабрь ае яңалыклары



**Они среди нас**

3 декабря - Международный день инвалидов. В школе, как и в стране идет декада инвалидов. Организованы конкурсы работ инвалидов, в том числе и детей- инвалидов, учащиеся оказывают тимуровскую помощь инвалидам, проходят воспитательные мероприятия в рамках декады. Учитель Гарипова Г.З. проводила утренник, посвященный этому дню.
*********************************
оо



**Пути повышения эффективности занятия - залог успеха в обучении.**
4 декабря на базе нашей школы состоялся районный семинар педагогов дополнительного образования на тему «Пути повышения эффективности занятия - залог успеха в обучении». Участники семинара обсуждали методы и формы активизации работы по использованию инновационных технологий в учебно-воспитательном процессе как фактор повышения эффективности обучения. Педагог дополнительного образования Шаипова Р.И. провела открытый урок в объединении «Мир шитья» на тему "Снятие мерок с фигуры человека".
*****************************

**"Дәреслекләр" рейды**

6 декабрьдә мәктәбебез китапханәчесе Х.Н.Нигъмәтҗанова китапханә активы белән берлектә дәреслекләрнең йөртелешен һәм сакланышын тикшерү буенча рейд үткәрде. Рейд нәтиҗәләре буенча I урында I һәм III сыйныф укучылары. (Сыйныф җитәкчесе - Гарипова Г.З.) V - VIII сыйныфта укучылар II урында. Ә менә II, IV, IX сыйныф укучыларына алда телгә алынган сыйныфлардан үрнәк алырга кирәк. Укучылар, безгә аң-белем, тәрбия бирүче дәреслрәребезне кадерләп тотыйк, тиешенчә файдаланыйк!

# УКЫРГА, УКЫРГА ҺӘМ УКЫРГА!

Безнең төп бурычыбыз һәм максатыбыз - тырышып уку. Мәктәптә укуның сыйфатын күтәрү максатыннан төрле эшләр башкарыла. Без төрле олимпиадаларда, тестлаштыруда, фәннә-практик конференцияләрдә катнашабыз. Бу уку елында V сыйныфтан Рахматуллина Энҗе, VI сыйныфтан Саидова Муниса, VII сыйныфтан Гыйльметдинова Ләйлә, Ибраһимов Рүзәл, VIII сыйныфтан Аскаров Данис, Даутова Дилбәр, Сафиуллина Илүзә, IX сыйныфтан Гыйльметдинова Гөлшат, Гыйльметдинов Инсаф, Мостафин Булат фән олимпиадаларының муниципаль турында катнаштылар. Җиңүчеләр сафына баса алмасалар да, уңай нәтиҗәләр күрсәтүчеләр дә булды. Менә алар: географиядән Гыйльметдинова Ләйлә, Мостафин Булат (җитәкчеләре: Ф.Г.Аскарова), математикадан Рахматуллина Энҗе (җитәкчесе: Г.Ә.Галимҗанова), Мостафин Булат (җитәкчесе: Н.Н.Әхмәтҗанова), татар теленнән Гыйльметдинова Гөлшат (җитәкчесе: Н.Н.Хуҗина).

Быелгы декабрь ае, укучылар өчен тестлаштыру ае булып та, истә калачак. Чөнки IV сыйныфтан алып IX сыйныфка кадәр һәр укучы, 3 тән башлап 7 гә кадәр фәннән, Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан оештырылган тестлаштыру үтте.






## Белем, гыйлем турында мәкальләр

- Дөнья яктыра көн белән,
  Адәм яктыра белем белән.
- Җиде йортның телен бел,
  Җиде төрле белем бел.
- Гыйлем алу – энә белән кое казу.
- Икми иген шытмас,
  Өйрәнми белем йокмас.
- Гыйлем акчага килми,
  Тырышлык белән килә.
- Гыйлем китапның эчендә дә, тышында да була.
- Белемнең чиге юк.
- Белем тәҗрибәдән килә.

*Сәхифәне әзерләүче: Даутова Дилбәр*

# Туган көннәрегез котлы булсын!

Хөрмәтле укытучыбыз Рәхмәтуллина Айгөл Әбүзәровна!

Сезне үзегезгә генә хас бәйрәмегез, Туган көнегез белән тәбрик итәбез. Сезне туган көнегез белән котлап, иң изге, якты, матур теләкләребезне юллыйбыз: көчле рухлы һәм кешелекле, юмарт һәм ярдәмчел, бәхетле һәм сәламәт булыгыз! Уй-теләкләрегез тормышка ашсын, туар таңнарыгыз тыныч, саулыгыгыз нык, гомерегез бәхетле булсын!

Җир йөзенең бөтен матурлыгын
Килә Сезгә бүләк итәсе.
Дөньядагы матур сүзләрнең дә
Иң җылысын килә әйтәсе.
Кояш мәңге көлсен Сезгә
Юлыгызга үссен гөлчәчәк.
Бүгенге көн гүзәллегеннән дә
Гүзәл булсын Сезнең киләчәк.

Укучылардан: I сыйныф укучысы Рәхмәтуллина Диана (27.12.2006), III сыйныф укучысы Гыймадиев Илүс (13.12.2004), VI сыйныф укучылары Саидов Абдулвахоб (12.12.2000), Шәйхетдинов Фирдүсләрнең (13.12.2001) декабрь аенда туган көннәре.

## Кадерле укучылар!

Сезне Туган көннәрегез белән тәбрик итәбез. Сезгә аяз күк йөзе, корычтай нык сәламәтлек, кояштай озын гомер, чиксез шатлыклар телибез. Мәрхәмәтле, ярдәмчел, кадерледән кадерле булыгыз. Һәрвакыт киң күңелле, ачык йөзле, олы йөрәкле булырга тырышыгыз. Ходай насыйп итеп сезгә әти-әниләрегез белән алдагы көннәрегездә дә сәламәтлек белән гомер итәргә, шатлыкларыгызга, уңышларыгызга сөенеп яшәргә язсын. Әти-әниләрегезгә игелекле балалар булыгыз.

*Котлауларны әзерләүче: Шәнгәрәев Рушан*

# ********* КАР СЫННАРЫ АЛЛЕЯСЫ - 2013 *********





















Газетаны гамәлгә куючы: Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Кече Кибәхуҗа төп мәктәбе

Адрес: 422080, ТР, Теләче районы, Кече Кибәхуҗа авылы, Кече урамы, 10 нчы йорт

e-mail: mkidiakozi40@mail.ru

Редактор: Галимҗанова Гөлнур Әхмәтзәкиевна, VIII сыйныф җитәкчесе

Редколлегия әгъзалары: VIII сыйныф укучылары